**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АЛЕКСЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ**
**“АЕРЫМ ПРЕДМЕТЛАРНЫ ТИРӘНТЕН ӨЙРӘНЕЛӘ ТОРГАН**
**2 НЧЕ АЛЕКСЕЕВСК УРТА ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРУ МӘКТӘБЕ**
**МУНИЦИПАЛЬ БЮДЖЕТ ГОМУМИ БЕЛЕМ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**

**«КАРАЛДЫ»**
МБ житәкчесе
________Замалиева И.Х.
МБ утырыш беркетмәсе
№1 24.08. 2017 ел

**«КИЛЕШЕНДЕ»**
“2 нче Алексеевск УГББМ”
МГБГУ директор
урынбасары
________Ягудина Л.Р.
25. 08. 2017 ел

**«РАСЛАНДЫ»**
“2 нче Алексеевск УГББМ”
МБГБУ директоры
________Дипляпина Л.Н.
264 номерлы боерыгы
1.09. 2017 ел

**Татар теле һәм татар әдәбияты укытучысы**
**Хәбибрахманова Халисә Харис кызының**
**1 “А” сыйныфы өчен татар теленнән**
**эш программасы**

Педагогик совет
утырышында кабул ителде
2 нче номерлы беркетмә
31 нче август 2017 нче ел

2017-2018 нче уку елы

1 нче сыйныф өчен татар теленнән эш программасы түбәндәге документларга нигезләнеп төзелде

**Программа түбәндәге документлар нигезендә төзелде:**

1. Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан рөхсәт ителгән “Гомуми белем бирү оешмаларында рус телендә сөйләшүче балалар өчен татар телен укыту программасы”. Казан. Татарстан китап нәшрияты. 2017 ел. Авторлары : Р.З.Хәйдәрова, К.С.Фәтхуллова, Г.М. Әхмәтҗанова.
2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем бирү мәктәбе”нең төп гомуми белем бирү баскычында башлангыч гомуми белем бирү программасы.
3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем учреждениясе “Аерым предметларны тирәнтен өйрәнүче Алексеевск 2 нче урта гомуми белем мәктәбе”нең 2017-2018 уку елына укыту планы **(№ 2 педсовет протоколы, 31 август 2017 ел).**

**Дәреслек**. Татар теле. Күңелле татар теле. Рус телендә башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен өйрәнүче укучылар өчен)
Төзүчеләре:Р.З. Хәйдәрова, Г.М. Әхмәтҗанова, Л.Ә.Гыйниятуллина Татар теле китабы. Ике кисәктән тора. Казан. «Татармультфильм» нәшрияты, 2014 ел

Программа 99 сәгатькә исәпләнгән, укыту программасында барлыгы 99 сәгать.

“Татар теле һәм әдәби уку” предметы буенча 1 нче сыйныф программасын үзләштерүнең **шәхси нәтиҗәләре**:

– татар теленең дәүләт теле буларак ролен аңлау;

– шәхесара һәм мәдәниара аралашуда татар телен куллануга уңай караш булдыру;

– татар теленә карата ихтирамлы караш булдыру һәм аны яхшы өйрәнү теләге формалаштыру.

--Әхлакый кагыйдәләрдә ориентлашу, аларны үтәүнең мәҗбүрилеген аңлау.

Татар теленә өйрәтүнең **метапредмет (***регулятив, коммуникатив, танып-белү)* **нәтиҗәләре**:

– укытучының күрсәтмәләрен аңлап үти белү;
– эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыра белү;
– дәрескә кирәкле уку-язу әсбапларын әзерли белү, алар белән дөрес эш итә белү;
– дәрестә эш урынын мөстәкыйль әзерли белү һәм тәртиптә тоту күнекмәләрен үстерү;
– әңгәмәдәшең белән аралаша белү күнекмәләрен формалаштыру;
– парларда һәм күмәк эшли белү;
– әңгәмәдәшең белән контактны башлый, дәвам итә, тәмамлый белү;
– үрнәк буенча эшли белү;
– аерым темаларга караган сорауларга җавап бирә белү;
– рәсем буенча җөмләләр, сораулар төзи белү;
– аңлап укый белү;
– укылган яки тыңланган мәгълүматның эчтәлегенә бәя бирү
- чагыштырып нәтиҗә ясый белү күнекмәләрен формалаштыру

Татар теленә өйрәтүнең **предмет нәтиҗәләре**.

**Сөйләшу**

**Диалогик сөйләм.** 1 нче сыйныфта дәрес вакытының 60-70%ын сөйләшүгә өйрәнү ала. Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- сайланган эчтәлек аша әңгәмәдәшең белән контакт урнаштыра, сорау куя, җавап бирә, кире кага, раслый белү;
- дәреслектә бирелгән үрнәк диалогларны сәнгатьле итеп уку, сөйләү һәм охшаш диалоглар төзү, программада күрсәтелгән коммуникатив максатлар буенча әңгәмәдә катнаша алу.

**Монологик сөйләм.** Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- җанлы һәм җансыз предметларны, рәсем, картина эчтәлеклеген сүрәтләп сөйли белү;
- программада күрсәтелгән темалар буенча кечкенә информация бирә белү.

**Ишетеп аңлау (аудирование)**

Аралашу өчен төп шартларның берсе – әңгәмәдәләрнең бер-берсенең сөйләмен аңлавы. 2 нче сыйныфта ишетеп аңларга өйрәтүнең бурычлары түбәндәгеләр:

- нормаль темп белән әйтелгәннең ишетү аша мәгънәсен аңларга, аңлаган турында фикер йөртергә, аралашуда кулана белергә өйрәтү;
- сүзләрне, сүзтезмәләрне, җөмләләрне, грамматик формаларны бер-берсеннән ишетү аша аерырга өйрәтү;
- ишетү хәтеренең күләмен үстерү.

**Уку**

Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбәндәге күнекмәләргә ия булырга

тиешләр:

- хәреф-аваз системасын аера, татар теленә хас булган авазларны дөрес әйтеп укый белү;
- дәреслектә уку өчен бирелгән җөмләләрне, текстларны дөрес интонация белән укый белү;
- укыган материалның эчтәлегеннән кирәкле мәгълүматны аерып ала белү;
- кечкенә күләмле шигырьләрне яттан сөйләү;
- укыганда сүзлекләр куллана белү.

Дәреслектә уку техникасын үстерүгә ярдәм итә торган рифмовкалар, җырлар, рифмалаштырылган әкиятләр бирелде. Үзләштерү дәрәҗәсенә карап, укытучы аларны арттыра яки киметә ала.

**Язу**

Сөйләм эшчәнлегенең бу төре буенча укучылар түбендәге күнекмәләргә ия булырга тиешләр:

- татар алфавитындагы хәрефләрне дөрес, матур яза белү;
- дөрес күчереп язу күнекмәләрен булдыру;
- бәйрәмнәр белән котлау язу.

## II. Укыту предметының эчтәлеге

1.Исемнәрнең берлек һәм күплек саннары.
2.Исемнәргә кем? нәрсә? соруларын куя белү.
3.Исемнәрнең 1,2,3 затта берлек санда тартым белән төрләнеше белән таныштыру.
4.Исемнәрнең урын-вакыт,юнәлеш,чыгыш килешләрендә төрләнеше белән танышу.
5.Зат алмашлыкларын берлек санда сөйләмдә куллану.
6.-мы-ме,түгел кисәкчәләрен,хәзерге заман хикәя фигыльнең юклык формасын(-мый-ми)сөйләмдә куллану.
7.Кайда? Кая? Кайдан? сорауларын кулланып төзелгән сорау җөмләләр белән таныштыру.
8.Микъдар һәм тәртип саннары белән таныштыру(1-20саннары).
9.Ничә? Ничек? Нинди? Нишли? Кайчан? сорауларына җавап бирә белү.
10.Белән бәйлеген сөйләмдә исем белән куллану.
11.Хәзерге заман хикәя фигыльнең 1,2,3 зат берлек сан формаларын сөйләмдә куллану.
12.Боерык фигыльнең 2 зат берлек Һәм күплек сан формалары белән таныштыру.
13.Бу күрсәтү алмашлыгын сөйләмдә куллану.
14.Сыйфат+исем төзелмәсен сөйләмдә куллану.
15.Һәм теркәгечен сөйләмдә куллану.
16.Сан+исем төзелмәсен сөйләмдә куллану.
17.Без зат алмашлыгының сөйләмдә кулланылышы белән танышу

## <u>III. Төп уку эшчәнлеге төрләре күрсәтелгән тематик планлаштыру</u>

| № т/с | Өйрәнелә торган бүлек, уку материалының темасы | Уку эшчәнлеге төрләре | Үткәрү вакыты: | |
|---|---|---|---|---|
| | | | Планлаштырылган срок | Фактик срок |
| 1. | **Әйдәгез танышабыз** . "Әйдәгез танышабыз!" темасы буенча әңгәмә. Сыйныфташларың, укытучы, китаптагы персонажлар белән танышу. | Әңгәмәдәш белән контактны башлау, дәвам итү, тәмамлау. | 5.09 | |
| 2. | Синең исемең ничек? соравы һәм аңа җавап формасы | Укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү. Дәреслектәге план буенча сөйли белү, дуслашырга тәкъдим итә белү. | 6.09 | |
| 3. | Бу кем?нәрсә?сораулары һәм аңа җавап формасы. *Бу кем?нәрсә?сорауларын куя белү.* | Әңгәмәдәшең белән аралашу калыбын төзү. | 8.09 | |
| 4. | Бу күрсәтү алмашлы. *Бу күрсәтү алмашлыгын сөйләмдә куллану.* | Укытучының соравына җавап бирәләр. **Бу** күрсәтү алмашлыгын сөйләмдә куллану. | 12.09 | |
| 5. | Раслау һәм кире кагу формалары | Парларда үз фикерен әйтәләр.Чагыштыралар. | 13.09 | |
| 6. | -мы/-ме сорау кисәкчәләре | Яңа материалны үзләштерү буенча үз фикерләрен әйтәләр. (Нәрсәне аңладылар? Нәрсә аңлашылмады? Ни өчен?) | 15.09 | |
| 7. | Бу кайсы шәһәр? соравы. Ялгызлык исемнәр. | Мәгълүматны туплау өчен күмәк эш башкару, фикерне төгәл итеп җиткерү.Ялгызлыкисемнәренбашхәрефтәнбашлапязу. | 19.09 | |
| 8. | *Син кайда яшисең?* соравы һәм аңа җавап формасы. Мин Алексеевскида яшим. | Исемнәрнең килеш белән төрләнешен аңлау. Әңгәмәдәшнең аралашу холкы белән идарә итү; коммуникатив мәсьәләгә таянып фикерне төгәл итеп җиткерү. | 20.09 | |
| 9. | 1 дән 10 га кадәр саннар. *Микъдар саннары белән таныштыру (1-10 саннары).* | Укытучы ярдәме белән максат кую, эшне планлаштыру. | 22.09 | |
| 10. | “Әйдәгез танышабыз” темасын | *Сиңа ничә яшь?* соравы | 26.09 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | йомгаклау. | һәм аңа җавап формасыПарларда үз фикерен әйтәләр. Чагыштыру. | | |
| 11. | **Урман дусларыбыз**. Аа хәрефе. *Исемнәрнең берлек һәм күплек саны*. | Тиешле мәгълүматны табу, билгеләү, сөйләм берәмлекләрен логик тәртипкә салу. [а] авазын дөрес әйтү, а хәрефен дөрес язарга өйрәтү. Кыргый хайваннарның исемнәрен берлектә һәм күплектә куллану. | 27.09 | |
| 12. | Әә хәрефе. Ничә? соравына җавап бирү. | Өйрәнелә торган орфограммаларны ишетеп аңлау. Хәреф элементларын атау, башлану ноктасын билгеләү, үрнәк буенча язу.**Ничә?** соравынаҗавапбирү. | 29.09 | |
| 13. | Оо хәрефе. Калын һәм нечкә сузыклар. | Сингармонизм законы белән танышу. .Билгеле күрсәтмә нигезендә эшли белү, нәтиҗә ясау. Баш һәм юл хәрефләрен язарга өйрәнү.Үз хезмәтеңне оештыру. Урман дусларыбыз темасына сөйләшү. | 3.10 | |
| 14. | Өө хәрефе. *Нинди?соравы һәм аңа җавап формасы* | ***Нинди?***соравы һәм аңа җавап формасы.Әңгәмәдәшенең фикерен тыңлый белү. | 4.10 | |
| 15. | **Спорт бәйрәме.** Нн, ң хәрефләре. Боерык фигыль. | Боерык фигыль.турында төшенчәне аңлау. Биремне эшләгәндә, кулланылган кагыйдәне аңлату. | 6.10 | |
| 16. | Ии хәрефе. *Боерык фигыльнең 2 нче зат берлек сан формасы белән таныштыру*. | Тексттан кирәкле төшенчә, мәгълүматны эзлиләр, табалар. | 10.10 | |
| 17. | Ыы хәрефе. Хикәя фигыльнең хәзерге заман 3 нче затта берлек сан формасы | Хикәя фигыльнең хәзерге заман 3 нче затта берлек сан формасын дөрес куллану.Дәрес максатын дәрес нәтиҗәсе белән бәйләү. | 11.10 | |
| 18. | Уу хәрефе. Ризалык белдерү формасы | Ризалык белдерү формасын аңлап куллану.Парларда үз | 13.10 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | фикерен әйтәләр. Чагыштыру. | | |
| 19. | Үү хәрефе. Микъдар саннары янында исем. | Дәрестә үз эшчәнлекләренә нәтиҗә ясау. *Ничә?* соравы һәм аңа җавап формасын ныгыту. Микъдарсаннары янында исемнең берлек санда килүен дөрес куллану. | 17.10 | |
| 20. | *Т*тхәрефе. *Уйный* фигыленең I, II затларда төрләнеше. | Укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү | 18.10 | |
| 21. | Лл хәрефе.*Белән* бәйлеге. | Укытучының соравына җавап бирәләр. *Кем белән уйныйсың?* соравы һәм аңа җавап формасын аңлау. | 20.10 | |
| 22. | Кк хәрефе. *Тәртип саннары белән таныштыру.* | Үзеңнең һәм иптәшеңнең җавабына бәя бирү. | 24.10 | |
| 23. | *Исемнәрнең 1, 2 затта берлектә тартым белән төрләнеше.* | Исемнәрнең 1, 2 затта берлектә тартым белән төрләнеше белән таныштыру.Уку-язу әсбапларының кемгә икәнен, аларның барлыгын, юклыгын, кирәклеген хәбәр итү (сорау); үзеңә сорап алу, иптәшеңә тәкъдим итү. | 25.10 | |
| 24. | **Мәктәптә**. Мм хәрефе. Хикәя һәм сорау җөмләләр. | Уку-язу әсбапларының кирәклеген әйтү, үзеңә сорап алу белү формасыХикәя һәм сорау җөмләләрне интонацион яктан дөрес әйтергә гадәтләндерү. Җөмлә ахырында дөрес тыныш билгеләрен куеп язарга күнектерү. | 27.10 | |
| 25. | Сс хәрефе. “Без дәрестә” темасы буенча әңгәмә. | Орфограммаларны табу,билгеләү. Тиешле мәгълүматны табу, билгеләү, сөйләм берәмлекләрен логик тәртипкә салу. | 7.11 | |
| 26. | *Кайда?* соравы һәм аңа җавап формасы | Чагыштыралар.Текст укыйлар. | 8.11 | |
| 27. | Рр хәрефе. “Мәктәптә” темасы буенча аралаша белү | Өйрәнелгән лексик, грамматик материалның | 10.11 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | күнекмәләрен ситуатив күнегүләр аша тикшерү. | үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү. Укудагы уңышларга, уңышсызлыкларның сәбәбен аңлый, анализлый белү. | | |
| 28. | **Йорт хайваннары һәм кошлары** В,в хәрефе. Сүз басымы. | Сүзләрдә басымны дөрес кую.Дустыңның тышкы кыяфәтен һәм характер сыйфатларын ачуда сүзләрне урынлы һәм аңлап куллану. Йорт хайваннары һәм кошлары исемнәрен хәтердә калдыру. | 14.11 | |
| 29. | Гг хәрефе. *Хикәя фигыльнең берлек сан I, II зат формасы. Хәзерге заман хикәя фиылнең 1.2,3, зат формаларын берлектә сөйләмдә куллану* | *Яши* фигыленең берлек сан I, II зат формасы. Фикерне төгәл җиткерә белү. Мәгълүматны туплау өчен күмәк эш башкару. | 15.11 | |
| 30. | Дд хәрефе. *Кая?* соравы һәм аңа җавап формасы | Сүзләр, җөмләләр язу. Күнегүләр эшләү. | 17.11 | |
| 31. | Зз хәрефе. Сыйфат. | Хайваннарны сыйфатларны кулланып сурәтләүӘңгәмәдәшең белән аралашу калыбын төзү. Образга бәя бирү. | 21.11 | |
| 32. | Бб хәрефе. *Кая? Кемгә?* сораулары һәм аларга җавап формасы | Әңгәмәдәшнең аралашу холкы белән идарә итү; коммуникатив мәсьәләгә таянып фикерне төгәл итеп җиткерү. | 22.11 | |
| 33. | Пп хәрефе. *Кайдан?* соравы һәм аңа җавап формасы. | Әңгәмәдәш белән контактны башлау, дәвам итү, тәмамлау. | 24.11 | |
| 34. | Ее хәрефе. *Кая? кайда? кайдан? сораулары һәм аларга җавап бирә белү.* | *Кая? кайда? кайдан?* сораулары һәм аларга җавап формасын куллану. Биремне эшләгәндә, кулланылган кагыйдәне аңлаталар. | 28.11 | |
| 35. | Ээ хәрефе. Исемнәрнең I зат берлек сан тартым белән төрләнеше. | Исемнәрнең I зат берлек сан тартым белән төрләнешен сөйләмдә куллану. Үзара тикшерү, үз-үзләрен тикшерү үткәрәләр. | 29.11 | |
| 36. | Йй хәрефе. Гади тотрыклы гыйбарәләр, татар сөйләм этикеты | Тыныч йокы, хәерле иртә | 1.12 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | берәмлекләре, клишелар.<br>Йорт хайваннары һәм кошлары темасын йомгаклау. | теләү. Әдәпле сүзләр кулланып, тормыштан алынган ситуацияләр буенча сөйләшү, киңәшләр бирү. | | |
| 37. | **Бакчада .** Жж хәрефе. “Бакчада” темасындагы лексик-грамматик күнекмәләр | Яшелчә исемнәренең дөрес язу.Сүзләр, җөмләләр язу. | 5.12 | |
| 38. | Модаль сүзләр *(кирәк, кирәкми)* | *Кирәк, кирәкми* сүзләрен дөрес аңлау. Чылбыр буенча кабатлыйлар.Орфограмма ларны табу,билгеләү. | 6.12 | |
| 39. | Җҗ хәрефе. Яңгырау һәм саңгырау тартыклар. | Яңгыраущһәмсаңгыраутарт ыкларныаерыргаөйрәнү.Җ иләк-җимеш исемнәренең дөрес язылышын куллану. Дәфтәргә күнегү эшләү, аңлату.Мисаллар китерү. | 8.12 | |
| 40. | ***Сыйфат+исем** төзелмәсе.* | **Сыйфат+исем** төзелмәсен сөйләмдә куллану.*Нинди?* соравы һәм аңа җавап формасын аңлап куллану. Укытучының һәм бер-берсенең сорауларына җавап бирәләр. | 12.12 | |
| 41. | Шш хәрефе. Мин ... яратам төзелмәсе. | Нәрсә яратканны, яратмаганны әйтү, сорау формаларын куллану. Әңгәмәдәшнең аралашу холкы белән идарә итү; коммуникатив мәсьәләгә таянып фикерне төгәл итеп җиткерү. | 13.12 | |
| 42. | Щщ хәрефе. “Безнең бакчада” темасы буенча әңгәмә | Лексик – грамматик күнекмәләрне камилләштерү .Җөмләдә дөрес куллана белү | 15.12 | |
| 43. | Чч хәрефе.“Бакчада” темасы буенча аралаша белү күнекмәләрен ситуатив күнегүләр аша тикшерү. | Сүз тәртибен дөрес кулланып җөмләләр төзү.*Кем? нәрсә? нишли?* сораулары һәм аларга җавап формалары. | 19.12 | |
| 44. | **Кыш җитте**. Хх хәрефе. Кыш билгеләре темасындагы лексик-грамматик күнекмәләр. | Яңа лексик берәмлекләр үзләштерү | 20.12 | |
| 45. | Һһ хәрефе.*-мы/-ме, түгел, әле кисәкчәләрен сөйләмдә куллану.* | **-мы/-ме, түгел, әле** кисәкчәләренсөйләмдәкул лану. Кышкы уенга чакыру. Әңгәмәдәш белән | 22.12 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | контактны башлау, дәвам итү, тәмамлау. | | |
| 46. | Фф хәрефе.**Эш кәгазьләре стиле. Хат язу.** | Кыш бабайга хат язабыз. Эпистоляр жанр текстларын дөрес язу. Үрнәк буенча эшләү. Яңа лексиканы кулланып, хат язуга ирешү | 9.01 | |
| 47. | Цц хәрефе. *Минем чанам бар* төзелмәсе | Фикерне төгәл җиткерү. | 10.01 | |
| 48. | Раслау һәм инкарь итү. | Алган белемнәрне мөстәкыйль куллану. -мы/-ме сорау кисәкчәләрен кулланып, сорау бирү; раслау һәм инкарь итү. | 12.01 | |
| 49. | *Кая? кайда? кайдан?* сорауларына җавап бирү. | Лексик – грамматик күнекмәләрне камилләштерү .Җөмләдә дөрес куллана белү | 16.01 | |
| 50. | Яя хәрефе. “Яңа ел бәйрәме” темасы буенча әңгәмә. | Сүз тәртибен дөрес кулланып җөмләләр төзү. | 17.01 | |
| 51. | Юю хәрефе. **һәм** теркәгечен сөйләмдә куллану. | Һава торышы турында план буенча сөйләү. **Һәм** теркәгечен сөйләмдә куллану. | 19.01 | |
| 52. | ь һәм ъ хәрефләре. Төсләрне белдерүче сыйфатлар. | Иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру | 23.01 | |
| 53. | Татар алфавитындагы хәрефләр тәртибе | Татархәрефләренең кабулителгәнформаларын дөресязу.Укыганны гомумиләштерә, нәтиҗә ясый, иң мөһим мәгълүматны аерып ала белү. | 24.01 | |
| 54. | Татар теленә хас авазлар. | Татар теленә хас авазларны кабатлау. Матурһәмдөресязукүнекмәләрен ныгыту.Өйрәнелгән лексик, грамматик материалның үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү | 26.01 | |
| 55. | **Сәламәт бул** . Тән әгъзаларының исемнәре темасындагы лексик-грамматик күнекмәләр. | Яңа лексик берәмлекләр үзләштерү. Сүз тәртибен дөрес кулланып , җөмләләр төзү. | 30.01 | |
| 56. | Кай җирең авырта? соравы һәм | Зат алмашлыкларын | 31.01 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | аңа җавап формасы | куллану. Сорау җөмләләр төзү күнекмәләрен камилләштерү.<br>Җөмлә ахырында сорау, нокта, өндәү куеп, язу күнекмәләрен гомумиләштерү | | |
| 57. | Хикәя фигыльнең юклык формасы | *Авырта* фигыленең юклык формасын дөрес куллану.Сүз тәртибен дөрес кулланып җөмләләр төзү. | 2.02 | |
| 58. | Татар һәм рус телләрендәге сузык һәм тартык авазларны чагыштырып, дөресәйтә белү, транскрипция билгеләре белән таныштыру. | Шәхси гигиена предметларының исемнәрен транскрипция белән язу.Яңа лексик берәмлекләр үзләштерү. | 6.02 | |
| 59. | Сүзләрне иҗекләргә бүлү, иҗекләп икенче юлгакүчерү. | *Мин сабын белән кул юам* төзелмәсе.Әңгәмәдәшенең фикерен тыңлый белү.Сүзләрнеиҗекләргәб үлү, иҗекләпикенчеюлгакүчер ү.<br>Иҗеккалыпларынанигезлә нгәнукукагыйдәләренгамә лиүзләштерү. | 7.02 | |
| 60. | Аралаша белү күнекмәләрен ситуатив күнегүләр аша тикшерү. “Сәламәт бул!” темасын йомгаклау. | Өйрәнелгән лексик, грамматик материалның үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү. “Сәламәт бул!” темасы буенча ситуатив күнегүләрне үтәү. | 9.02 | |
| 61. | **Безнең гаилә**. Гаилә әгъзаларының исемнәре.*Зат алмашлыкларының берлектә баш, иялек килешләре.* | Зат алмашлыкларын берлектә баш, иялек килешләрендә сөйләмдә куллану белән таныштыру.Яңа лексик берәмлекләр үзләштерү. Сүз тәртибен дөрес кулланып , җөмләләр төзү. (Мин, минем, миңа) | 13.02 | |
| 62. | “Минем гаиләм” темасы. Җөмлә ахырында тыныш билгеләре. | Җөмлә ахырында сорау, нокта, өндәү куеп, язу күнекмәләрен гомумиләштерү | 14.02 | |
| 63. | Гаилә әгъзаларының нишләгәнен әйтү. Җөмләне баш хәрефтән яза башлау. | Сорау җөмләләр төзү күнекмәләрен камилләштерү. | 16.02 | |
| 64. | Яз турында сөйләшү. | План буенча сөйли белү. | 27.02 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 65. | Озын һәм кыска сузыкларны сүзләрдә дөрес итеп әйтә белү. | Язгы көн турында сөйләшү.Озынһәмкыскасузыкларнысүзләрдәдөреситепәйтәбелү.Фикерне төгәл җиткерә белү. Сүзне юлдан юлга күчерүгә күнегүләр эшләү. | 28.02 | |
| 66. | Һава торышы турында сөйләшү. Боеру максаты белән әйтелгән җөмләләр. | Боеру максаты белән әйтелгән җөмләләрне аңларга өйрәнү.Укытучы ярдәме белән максат кую, эшне планлаштыру. | 2.03 | |
| 67. | 8 нче Март – әниләр бәйрәме турында сөйләшү. | Җөмлә ахырында сорау, нокта, өндәү куеп, язу күнекмәләрен гомумиләштерү | 6.03 | |
| 68. | **Эш кәгазьләре стиле.**Бәйрәм белән котлый белү. | Котлау язу күнекмәләрен мөстәкыйль куллана белү | 7.03 | |
| 69. | Аралаша белү күнекмәләрен ситуатив күнегүләр аша тикшерү. “Безнең гаилә” темасын йомгаклау. | “Мин кемгә бүләк бирәм?” соравына җавап бирү. Алган белемнәрне мөстәкыйль куллана белү | 9.03 | |
| 70. | **Татар халык ашлары**. Татар халык ашларының исемнәре темасындагы лексик-грамматик күнекмәләр. | Яңа лексик берәмлекләр үзләштерү. Сүз тәртибен дөрес кулланып , җөмләләр төзү. | 13.03 | |
| 71. | Сыйфат ясагыч кушымчалар (-лы, -сыз). | Ризыкларның тәмле булуын әйтү. Әңгәмәдәш белән контактны башлау, дәвам итү, тәмамлау.Матурһәмдөресязукүнекмәләребулдыру. | 14.03 | |
| 72. | Кунакта темасына сөйләшү. *Һәм теркәгечен сөйләмдә куллану.* | Табын янында үз-үзеңне тоту буенча киңәшләр бирә белү. иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру; | 16.03 | |
| 73. | Калын һәм нечкә сузыклар. Кунакны каршы алу. | Әңгәмәдәш белән контактны башлау, дәвам итү, тәмамлау. | 20.03 | |
| 74. | -мы/-ме сорау кисәкчәләрен кулланып мәгълүмат алу | Кисәкчәләрнең мәгънәләрен ачыклау өстендә эшләү. Кисәкчәләрнең дөрес язылышы буенча кагыйдәләр үзләштерү, язмада куллану. | 21.03 | |
| 75. | Туган көн – зур бәйрәм турында сөйләшү | Алган белемнәрне мөстәкыйль куллана белү | 23.03 | |
| 76. | Яңгырау һәмсаңгырау | Яңгырауһәмсаңгыраутарт | 4.04 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тартыклар.Туган көн белән котлау | ыкларныаерыру. Котлау язу күнекмәләрен мөстәкыйль куллану. Туган көн белән котлау. | | |
| 77. | **Кибеттә.** Ашамлык исемнәре темасындагы лексик-грамматик күнекмәләр. | Укытучы ярдәме белән максат кую һәм эшне планлаштырырга өйрәнү. | 6.04 | |
| 78. | *Хәзерге заман фигыльләренең I, II, III затта берлек саны* | *Эчә, ашый* фигыльләренең I, II, III затта берлек саны. Эш тәртибен аңлап, уку эшчәнлеген оештыру | 10.04 | |
| 79. | *Исемнәрнең төшем килеше белән таныштыру.* | Исемнәрнең төшем килеше белән танышу.Билгеле күрсәтмә нигезендә эшли белү, нәтиҗә ясау. Нәрсә ашыйбыз, нәрсә эчәбез? темасына сөйләшү. | 11.04 | |
| 80. | *Исемнәрнең юнәлеш килеше белән таныштыру.* | Исемнәрнең юнәлешкилеше белән таныштыру.Савыт-саба исемнәрен куллану. Мин калакны өстәл**гә** куям... төзелмәсен куллану. Яңа лексик берәмлекләр үзләштерү. Сүз тәртибен дөрес кулланып , җөмләләр төзү. | 13.04 | |
| 81. | Исемнәрнең урын-вакыт килеше белән таныштыру. | Исемнәрнең урын-вакыткилешләре белән танышу.Иҗади һәм эзләнү характерындагы проблеманы билгеләү, аларны чишү өчен алгоритм булдыру. Кибеттә савыт-саба сатып алу темасына сөйләшү. | 17.04 | |
| 82. | Савыт-саба кибетендә темасына сөйләшү. | Әңгәмәдәш белән контактны башлау, дәвам итү, тәмамлау. | 18.04 | |
| 83. | Исемнәрнең чыгыш килеше белән таныштыру. | Исемнәрнең чыгыш килеше белән танышу. Мин күлмәкне шкаф**тан** алам төзелмәсен куллану. Кием атамаларын дөрес әйтү.Яңа лексик берәмлекләр үзләштерү. Сүз тәртибен дөрес кулланып , җөмләләр төзү. | 20.04 | |
| 84. | Исемнәрнең берлек санда тартым белән төрләнеше. Киемнәр. | Алган белемнәрне мөстәкыйль куллана белү | 24.04 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 85. | **Без шәһәрдә яшибез. Шәһәрдә.** Шәһәрдә темасына темасындагы лексик-грамматик күнекмәләр. | Мәгълүматны туплау өчен күмәк эш башкару. | 25.04 | |
| 86. | *Зат алмашлыкларының берлектә баш, юнәлеш килешләре*. | Безнең шәһәр темасына сөйләшү.Тиешле мәгълүматны табу, билгеләү, сөйләм берәмлекләрен логик тәртипкә салу.Заталмашлыкларынб ерлектә баш, иялек, юнәлеш килешләрендә сөйләмдә куллану белән танышу. | 27.04 | |
| 87. | “Мин транспортта барам” төзелмәсе | Өйрәнгән грамматик структураларны дөрес куллану | 1.05 | |
| 88. | Ялгызлык һәм уртаклык исемнәр | Ялгызлык исемнәрнең язылышын истә калдыру. Татарстан шәһәрләре исемнәре. | 2.05 | |
| 89. | Исемнең юнәлеш килеше. Син кая барасың? | Лексик –грамматик материалны ныгыту. Җөмләдә дөрес куллана белү | 4.05 | |
| 90. | Исемнең чыгыш килеше. Син кайдан кайтасын? | Парларда үз фикерен әйтәләр.Чагыштыралар. | 8.05 | |
| 91. | Исемнәрнең урын-вакыт килеше. Син кайда яшисең?Кайдан кайтасың? | Лексик –грамматик материалны ныгыту Җөмләдә дөрес куллана белү | 9.05 | |
| 92. | Аралаша белү күнекмәләрен ситуатив күнегүләр аша тикшерү.“Шәһәрдә” темасын йомгаклау | Лексик – грамматик күнекмәләрне камилләштерү | 11.05 | |
| 93. | **Җәй**. “Җәй җитә” темасына сөйләшү | Җәйге табигать турында сөйли белү. | 15.05 | |
| 94. | Авызлар һәм хәрефләрне кабатлау. | Күңелле җәй темасына сөйләшү. Җәйге табигать турында сөйли белү. | 16.05 | |
| 95. | Нечкә һәм калын сузык авазларны кабатлау. | Җәйге ял темасына сөйләшү.Җәй көне нишләвең турында әйтә белү. | 18.05 | |
| 96. | Күчереп язу. “Безнең шәһәр” тестыннан өзек | Текстны дөрес каллиграфия белән, төзәтүләрсез, хатасыз язу. | 22.05 | |
| 97. | Алфавитны кабатлау. | Сабантуй бәйрәме турында фикер алышу. | 23.05 | |
| 98. | Без Сабантуйга барабыз темасына сөйләшү | Сабантуйда нишләвең турында әйтә белү. | 24.05 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 99. | Аралаша белү күнекмәләрен ситуатив күнегүләр аша тикшерү.“Җәй җитә” темасын йомгаклау. | Өйрәнелгән лексик, грамматик материалның үзләштерелү дәрәҗәсен тикшерү | 25.05 | |

Пронумеровано, прошнуровано
И скреплено печатью
15(пятнадцать) страниц
_______ Хабибрахманова Х.Х.